ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

26.08.2019 п.г.т.Алексеевское № 364

**2019-2020 уку елына Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы “Балалар иҗаты үзәге”өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе түләүле белем бирү хезмәтләре күрсәтү турында**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органы карамагындагы дәүләт бюджет учреждениеләре эшчәнлегенең төп төрләренә керүче хезмәтләр күрсәткән (эшләр башкарган) өчен гражданнарга һәм физик затларга Үрнәк түләү тәртибен билгеләүне раслау турында”гы 30.12.2010 ел, 1170 нче карары, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының “Татарстан Республикасы дәүләт (муниципаль) белем бирү учреждениеләре физик һәм юридик затларга күрсәтә торган түләүле хезмәтләр күрсәтү турында регламентны раслау турында”гы 06.05.2014 ел, 2556/14 нче Боерыгы нигезендә һәм мәктәпкәчә яшьтәге балаларны җайлашуга әзерләү, шулай ук Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы “Балалар иҗаты үзәге”өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесенең матди-техник базасын ныгыту максатында

**карар бирәм:**

1. 2019-2020 уку елына 2019 елның 1 сентябреннән Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы “Балалар иҗаты үзәге”өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесендә түләүле өстәмә белем бирү күрсәтүне оештырырга.

2. “Росточек” эстетик үсеш мәктәбендә өстәмә түләүле белем бирү хезмәтләре исемлеген расларга (1 нче кушымта).

3. 2019 елның 1 сентябреннән түләүле белем бирү хезмәтләре күрсәтүгә бәяләр прейскурантын расларга (2 нче кушымта).

4. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының “Бюджет һәм автономияле учреждениеләрнең бюджеттан тыш чаралары турында”гы 30.12.2016 ел, 21-53-24-3742 нче хаты нигезендә түләүле белем бирү хезмәтләре күрсәтүдән алынган акчаны түбәндәгечә сарыф итү тәртибен расларга:

- матди-техник базаны ныгытуга чыгымнар - 25%;
- хезмәткә түләүгә - 75%, шул исәптән:
- өстәмә белем бирү педагогына - 84%;
- административ-идарә итүче персоналга - 16 %.

5. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы "Балалар иҗаты үзәге"өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе директорына (Фәссахова Г.Г.) гамәлдәге закон нигезендә түләүле белем бирү хезмәтләре күрсәтү өчен шартлар тудырырга.

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Алексеевск муниципаль районы рәсми сайтында мәгълүмати-телекоммуникацион Интернет челтәрендә урнаштырырга.

7. Әлеге карарның үтәлешенә контрольлек итүне социаль мәсьәләләр буенча башкарма комитет җитәкчесе урынбасары Н.П.Чуринга йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **Н.К.Кадыйров**

Алексеевск муниципаль районы
башкарма комитетының
26.08.2019 ел, 364 нче карарына
1 нче кушымта

**2019 -2020 уку елына Татарстан Республикасы**
**Алексеевск муниципаль районы “Балалар иҗаты үзәге”өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе буенча түләүле өстәмә белем бирү хезмәтләре**

**ИСЕМЛЕГЕ**

| Тәртип саны | Хезмәт исемлеге | Белем бирү хезмәтләре төрләре | Төркемдә балалар саны | Дәресләр дәвамлылыгы |
|---|---|---|---|---|
| **"Росточек"эстетик үсеш мәктәбе** | | | | |
| 1 | "АБВГД-ка" | Авазлар һәм хәрефләрне өйрәнү, сөйләм телен үстерү, гармоталылыкка өйрәтү | 15 | Атнага 2 тапкыр 30 ар минут |
| 2 | “Хисаптан карарга” | Саннарны өйрәнү, фикерләү операцияләрен формалаштыру (анализлау, чагыштыру), логик фикерләүне үстерү, игътибар, күрү һәм ишетү хәтерен, күзаллауларны үстерү | 15 | Атнага 2 тапкыр 30 ар минут |
| 3 | «Баскычтан баскычка» | Контур буенча предметларны йөртеп чыгу, штриховка, буяу, хәреф элементлары белән танышу һәм аларны тоташтыру | 15 | Атнага 2 тапкыр 30 ар минут |
| 4 | Фантазерлар (рәсем, декоратив-гамәли сәнгать) | Рәсем, әвәләп ясау, конструкцияләү, иҗат белән шөгыльләнү | 15 | Атнага 2 тапкыр 30 ар минут |

**Башкарма комитетның**
**эшләр белән идарә итүчесе** **Г.Ә. Йосыпова**

Алексеевск муниципаль районы
башкарма комитетының
26.08.2019 ел, 364 нче карарына
2 нче кушымта

**2019 елның 1 сентябреннән бер укучыга Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы “Балалар иҗаты үзәге” өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе буенча түләүле өстәмә белем бирү хезмәтләре күрсәтүгә бәяләр**

**ПРЕЙСКУРАНТЫ**

| Тәртип саны | Хезмәт исемлеге | Белем бирү хезмәтләре төрләре | Төркемдә балалар саны | Дәресләр дәвамлылыгы |
|---|---|---|---|---|
| 1 | "АБВГД-ка" | Авазлар һәм хәрефләрне өйрәнү, сөйләм телен үстерү, гармоталылыкка өйрәтү | 225,00 | Айга 8 тапкыр 30 ар минут |
| 2 | «Хисаптан карарга» | Саннарны өйрәнү, фикерләү операцияләрен формалаштыру (анализлау, чагыштыру), логик фикерләүне үстерү, игътибар, күрү һәм ишетү хәтерен, күзаллауларны үстерү | 225,00 | Айга 8 тапкыр 30 ар минут |
| 3 | «Баскычтан баскычка» | Контур буенча предметларны йөртеп чыгу, штриховка, буяу, хәреф элементлары белән танышу һәм аларны тоташтыру | 225,00 | Айга 8 тапкыр 30 ар минут |
| 4 | Фантазерлар (рәсем, декоратив-гамәли сәнгать) | Рәсем, әвәләп ясау, конструкцияләү, иҗат белән шөгыльләнү | 225,00 | Айга 8 тапкыр 30 ар минут |

**Башкарма комитетның**
**эшләр белән идарә итүчесе** **Г.Ә. Йосыпова**